


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 6,Февраль, 2026 ел*




## Ничек бәйрәм итмисең, ди инде?!

Ир-егетләребез бәйрәме бит ул! Кайбер «кызу башлар» бу бәйрәмнең җетелеген күпме генә киметергә тырышмасын, 23 февраль безне яклаучыларыбыз – Ватанны саклаучыларыбызга хөрмәт күрсәтү көне булараk кала бирә, һәм тарих зилзиләләре үз кыйбласын ничек кенә үзгәртсә дә, ул шулай булып калачак та. Шуңа да бу көнне хәрби органнарда эшләүчеләрдән алып балалар бакчасына йөрүче малайларга кадәр барысына да бәйрәм котлауларыбызны юллыйбыз.

Ә инде бәйрәмнең тарихына килгәндә, ул совет чоры белән бәйле. 1918 елның 15 гыйнварында Халык Комиссариаты Советы «Эшче-крестьян Кызыл Армиясе төзү» һәм «Эшче-крестьян Кызыл Флотын төзү» турындагы декретлар кабул итә. Әмма нәкъ менә бу көнне билгеләп үтү рәсми төстә билгеләнми әле. Тарихи чыганаклар буенча 1918 елның 23 февралендә Кызыл Армия Псков һәм Нарва янында немец гаскәрләрен җиңүгә ирешә.

1922 елдан исә 23 февраль рәсми төстә Кызыл Армия көне дип игълан ителә. Бу көнне Реввоенсовет рәисе Троцкий Кызыл мәйданда хәрби парад оештыра һәм шуның белән ел саен гомумхалык тантанасы традициясен кертә. Тик шулай да 23 февральне рәсми төстә Кызыл Армия көне буларак билгеләп үтү 1938 елдан гына башлана. Ә 1946 елдан ул Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты көне дип йөртелә башлый. 1993 елдан башлап, 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне. Ә инде 2002 елдан бу көн ял көне санала.

Ватанны саклаучылар көне хакында сүз куертуыбыз әлеге бәйрәм якынлашу уңаеннандыр дип уйлавыгыз рас анысы. Һәр коллективта, һәр төбәктә, елдагыча, быел да бу бәйрәмне зурлап билгеләп үттеләр.

Безнең мәктәптә дә төрле чаралар үтте. “Зарница”уены, хоккей ярышлары, волейбол уены, чаңгы ярышы бик матур оештырылды. Иң истә калганы - 2026 елны - Хәрби батырлык һәм Хезмәт фидакарьлеге елын ачу тантанасы иде. Авылдышыбыз Хәкимҗанов Хәлил абыйга “Ил алдында күрсәткән батырлыгы өчен” медале тапшырылды. Патриотик җыр маршировкасы булды. Барыбыз да тырышып әзерләнде. Егетләребезне бәйрәм белән котладык. Чөнки алар киләчәктә илебезне саклаучылар булачак.

Шулай итеп, ир-егетләребезне – барча ил сакчыларын икеләтә бәйрәм белән!

**7 нче сыйныф укучысы Шакирова Камилә**

## Әти!



Нинди матур яңгырашлы, йө
исем. Ә аның янәшәсендә “
тагын да матуррак ишет
булганда гына хөр күңел
яшисең. Безнең әтиләр гаи
да, һаман , никтер әниләр к
килделәр. Әйдәгез , бүгенге к
яктылыкка чыгарыйк әле,
бик яхшы күңелле, ягымлы

Әти! Бу сүздә бик тирән мәгънә ята. Гаилә т
саклаучы ир – егет. Ниһаять- ил агасы.

Үз көчендә калсын , үзгәрмәсен
Борынгыдан калган бер өмет.
Ил агасы булып , әти булып,
Горур булып калсын ир-егет.

Хөрмәтле әтиләр! Сезнең барыгызны да Ватанн
белән котлыйм. Эшегездә, тормышыгызда зур уңы
һәм сәламәтлек телим.

**4 нче сыйныф укучысы Харасов Әмир**

## Сугыш чоры, канлы сугыш.

Сугыш чоры, канлы сугыш
Күпме гомерне суырды
Күпме хатын- кызлар, балаларны
Ятим итте, тол калдырды.
Килде илгә борчу, сагыш салып
Күпме авыл-шәһәрне җимерде.
Җиңсәк тә без, калды күңелләрдә
Үз тарихыбызга якын итте.
Үткән инде 80 ел
Шатланып искә алыйк
Бу көнне хәтеребездә
Мәңгегә онытмыйк.

**3 нче сыйныф укучысы Рашидова Сабрина**



## Кышкы матурлык

Ак мамык юрган капланган,
Ак бәсләр агачларда.
Без чана-чаңгы шуабыз
Табигать кочагында.

Бар да ак карга төренгән,
Ак җәймә япкан кебек.



## Футбол – минем яраткан спорт төрем

Спорт минем тормышта аерым урынны алып тора. Барлык спорт төрләре арасында иң ошаганы футбол. Күпләр спортны ярата. Минем уйлавымча, иң файдалы һәм кызыклы спорт төре ул - футбол. Футбол ул - житезләр уены, ул хәрәкәт. Туп белән уен сәламәтлекне ныгыта, үзеңне яхшы хис итәргә булыша.

Бала чакта әтием Казанда футбол стадионына алып барды. Беренче тапкыр шундый зур стадионны күрдем. Әле дә хәтерлим, уенчыларның йөгерү тизлегеннән, аларның зур футбол кырында үзара аралашып, матур уен күрсәтүләрен, төгәл көйләнгән гамәлләрен тын калып карап тордым. Әтием үзе дә кечкенә чагында футбол уйнарга яраткан. Бергә футбол уйнаганда төрле алымнар күрсәтә, кызыклы истәлекләр сөйләп ала. Каникул чорында гел бергә абый белән саф һавада туп уйныйбыз.

“Ашыт” спорт комплексында футбол белән даими шөгыльләнәм. Минем тренер - Валиуллин Тахир Рафкатович, ул шулай ук әтинең дә тренеры булган. Миңа биредә бик ошый, дүрт ел буена мин аерым уен алымнарына, күп техникаларга өйрәндем. Безнең командага минем кебек егетләр йөри, алар районның төрле авылларыннан киләләр. Команда белән төрле ярышларга йөрибез. 2024 нче елда “Первенство Республики Татарстан” ярышында катнашып, өченче урынны алдык. Футбол уены тактик фикерләү һәм команда эше, бу уенда ялгызың гына уңышка ирешә алмыйсың. Һәр уенчы үз иптәшләренә ышанырга, командада эшли белергә тиеш. Шулай итеп, футбол уены безне мөһим тормыш сыйфатларына, үзара ярдәмләшергә, жаваплылыкка өйрәтә. Уртак максат өчен бергәләп эшләү кирәк икәнен аңлыйсың. Хыялым киләчәктә футбол буенча яңа уңышларга ирешү, зур стадионнарда уйнау. Жанатарлар карап торганда тагын да уйныйсы килә, матур уен күрсәтәсе килә. Мәктәптә төрле спорт ярышлары булып тора. Хоккей на валенках уены уйнадык. Ул авылдашыбыз СВО да һәлак булган, Хәкимзянов Хәлил абый истәлегенә узды. Мәктәп янында каток бар, дәрестән соң без анда да шуабыз, хоккей уйныйбыз. Безнең Күәм авылында хоккей командалары да берничә. Без дә классташлар белән лаеклы алмаш булып үсәрбез

**6 нчы сыйныф укучысы Исхаков Данил**




Табигатьне саклыйк әле
Аның кадерен белеп.

**4 нче сыйныф укучысы Брча Амира**



**һөн**

һөн
без
кад
һөн
бик
язылган, жырлар жырланган. Туган ягым гүзәл дә, аның
якын тоела. Үсеп житкәч, һәр кеше үзенә якын, кадерле б
Ул аңа кечкенәдән тартыла. Нинди генә эшкә тотынсак та
юк икәнен белергә тиешбез. Әти-әниләребез дә үзләренең
тугрылыклы булып хезмәт куялар. Мин дә үсеп житк
тугрылыклы булып, Ватаныма хезмәт итәчәкмен. Һәр һө
файдалы. Кеше эшли алмаган эш, үзләштерә алмаган һөнә

Атнаның һәр пәнҗешәмбесендә без һөнәрләр
аларның кайсы өлкәләрдә кулланылганын, бу һөнәрләрн
нинди сыйфатлар булырга тиешлеген ачыклыйбыз.
кулланылыш өлкәсе турындагы видеороликлар кыз
Барыбызга да җәмгыятькә, илебезгә кирәкле, файда
житешергә насыйп булсын.

**7 нче сыйныф укучысы Шиһапова Диләрә**

## Мин нинди зур.

Мин инде зур үстем, өченче сыйныфта укыйм. Укудан
алдына чыгам. Карларны көрәп куям. Бабам миңа “Зур
арасына керә башладың, -ди. Әби кибеткә барганда ми
кайтканда аның авыр сумкаларын күтәрешәм. Әби: “ И а
улым,” –ди. Әнигә баздан бәрәңге алып чыгарга, әтиг
булышам. Мин чыннан да зур үстем шул.

**3 нче сыйныф укучысы Ахметшин Ильмир**



## Китапханәдә кунакта

Без бүген, 26 фе
китапханәсенә кунак
китапханәче Луиза апа
китапхана белән таныш
нән артык китап сакл
китаплар белән тан
тәрәзәлесен дә, күзлес
чәчәк формасындагысын да тотып, ачып, укып карадык.
дип матур матур китаплар алдык.

Китапханә белән танышкач, Луиза апа безгә Г.Тукай
иҗаты турында сөйләде. Уен-викторина үткәрде. Безг
шигырьләрен матур итеп сөйләде. Соңыннан без Тукай
җыйдык. Безгә китапханәдә бик ошады.

**1 нче сыйныф укучылары**

## Февральдә эшләгән эшләрем

Мин инде зур. Шуңа да эшләрем бик күп. Бу айда мин ай
әниемә булыштым.
23 нче февраль көнне без ял иттек, бәйрәм булды. А



## “Йолдызлык” фестивалендә

Минем исемем - Ильфия. Мәктәптә 3 нче сыйныфта укыйм. Дәресләрдән соң атнага 2 тапкыр Әтнә сәнгать мәктәбенең “ Вокал” дәресләренә йорим. Вокал укытучым - Абдуллина Ләйлә Рөстәм кызы. Мин кечкенәдән үк җырларга яратам,ә җырлаганда үземне чын- чынлап бәхетле итеп хис итәм.

Шулай ук еш кына концертларда да чыгыш ясыйм. Сәхнәгә чыгып басканчы бераз “куркыта”, әмма сәхнәгә чыгып басуга залдагы тамашачыларның елмаеп торган йөзләрен күру миңа көч бирә.

Вокал дәресләренә минем белән бергә тагын 5 классташым да йори. Ләйлә апаебыз безнең класс балалары белән “Дуслык” ансамбле оештырды. Февраль аенда районда “Йолдызлык” фестивалендә катнаштык.

Минем җыр сәнгате белән кызыксынуым дәвамлы булыр дип ышанам. Киләчәктә дә үземне зур сәхнәләрдә күрергә телим.

**2 нче сыйныф укучысы Гатауллина Илфия**

## Мәрҗани – таңыбыз Чулпаныдыр...

Ш.Мәрҗани – татар халкы язмышында якты эз калдырган кеше. Аның хезмәтләре һәм киң колачлы эшчәнлеге халкыбызны урта гасыр туңлыкларыннан, катып калганлыктан арындыруда мөһим роль уйнады. Аның тарафыннан барлыгы 30дан артык фәнни хезмәт язылды. Аларда фәлсәфә һәм илаһият тәгълиматы (богословие) проблемалары, тарих һәм мәдәният мәсьәләләре яктыртыла. Аның күпкырлы мирасында “Мөкаддимәте катабе Вафийәт әл – әсләф вә тәкийәт әл – әхләф” дигән фәлсәфи – теоретик хезмәт аерылып тора. Бу зур күләмле китап 1883 нче елны Казанда гарәп телендә басылып чыга. Ул тирән эчтәлекле теоретик әсәр. Анда автор үзенең тарихи процесска, төрле фәннәрнең барлыкка килүе һәм таралуына карата булган карашларын бәян итә, фәлсәфи – методологик проблемаларның илаһият тәгълиматына кагылышлы мәсьәләләрне яктырта. Китапта Ш.Мәрҗани шулай ук фәннәргә классификация бирә, аларның роль һәм функцияләре турында сүз алып бара.”Мөкаддимә” дә гарәпләрнең борынгы тарихы, ислам тарихы, гарәп теле һәм әдәбият мәсьәләләре дә үзләренең чагылышын табалар.

Гомумән, Ш.Мәрҗани – күп кырлы талант иясе, тарихчы, галим, мөгаллим.

Безнең районда 18 февраль көнне X нчы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге районара фәнни – гамәли конференция үтте. Без анда катнашып, призлы урыннар яуладык. Киләчәктә дә аның эшчәнлеге, тормышы турында эзләнү эшләрен туктатмабыз, өйрәнербез дип ышынып калам.

**9 нчы сыйныф укучысы Галимҗанова Әдилә**

“Аҗаган” уены уйнадык. Бу уен миңа бик ошый. Ап – ак йөзәсең. Бу уенда без: учак яктык, флажок эзләдек. Без урын яуладык.

Әниемә булышам. Өйләр җыештырышам, гөлләргә су Дәресләремне дә онытмыйм.

Аннан соң әтиемә тышты эшләргә булышам. Гараж ремонтлашам.

Соңрак дусларым белән хоккей карарга барам. Үзем да чаңгыда шуам. Волейбол уйнарга яратам.

Менә шулай. Ничек күп минем эшләрем. “Эш эшла минем әти. Әти миңа үрнәк - ул. Әтинмне бәйрәм сәламәтлек телим.

**5 нче сыйныф укучысы Якубов Рәсим**


## Гәҗитне басмага әзерләделәр

**Баш мөхәррир: Сөнгатова Г.З.**

**8 нче сыйныф укучысы :Шакирова Камилә.**

**6 нчы сыйныф укучысы: Галявиева Алия.**

**10 нчы сыйныф укучысы:Гатауллина Илүзә.**